**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2020 ел** **№2**

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Сарлы авыл җирлеге Сөендек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- янгын сүндерү автомобиле йөртүче хезмәтенә түләү, янгын сүндерү автомобиле өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу;
- Сөендек авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сөендек авылы зиратларын карап тоту (перфоратор һәм генератор сатып алу);
- Сөендек авылы Кооператив урамы буенча юлны ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Азнакай муниципаль районы Сөендек авыл җирлеге гражданнарының 2020 елда җыелган һәм кулланылмаган 33 мең сум күләмендә үзара салым акчаларын 2021 елда түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлдерергә:

- Сөендек авылы Кооператив урамы буенча юлны ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү).

4. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге башлыгы М.Р.Шәрипов